# Тәвәккәллек, батырлыкта Җыр булып калсам иде.

Фатих Кәрим иҗатына багышланган презентация

# Фатих Кәримнең тормыш һәм иҗат юлы.



**1909 елның 9 гыйнварында Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында Әхмәтвәли мулла гаиләсендә унберенче – төпчек бала булып дөньяга килә.**

# Белемгә омтылыш

Ает (1909) башлангыч мәктәп

Бәләбәй (1922) педагогия техникумы

Казан (1924) җир төзелеше техникумы


Детск.жур. «Юные Товарищи»
Орган Татбашбюро ЦКВЛКСМ
Адрес: Москва, Никольская, 10

# كچكنه ئيبده‌شله‌ر

ئوكتەبر – 1927

10 (42) نچى نومير

يەشەسن، ئيزلگەن حالقلارنى
ئازادلققا چاروچى ئوكتەبر!

ئه‌تيبز نشچى-ئيگنچى‌نڭ
قوچاعندا ئوسه ئوكته‌بر.
10 يل ئيندى بزده‌ئوكته‌برنڭ
ئوتلى قوچاعندا ئوسه‌بز.
بزنڭ كوڭلەر-يەشن تيزلگندە
كامموناعا كوچو ميزگللى.

ئوكتەبر كورگەزمەسئ

Ф. Кәримнең “Хәзер сезнең белән” исемле беренче шигыре “Кечкенә иптәшләр” журналының 1927 елгы икенче санында дөнья күрә.



Җир төзелеше техникумында укыганда булачак әдип ныклап әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеккә тартыла. А. Алиш, Г.Минский, М. Әмир һәм башка бик күп дуслар таба.

**Рәсемнәрдә Фатих Кәрим үзенең якын дуслары белән.**





Татарстан язучылар оешмасы каршында эшләгән әдәбият түгәрәге членнары арасында (уңнан сулга) беренче рәттә  Фатих Кәрим.







Тәрәзәмә кунган ак күгәрчен
Гөрли-гөрли канат кагына.
Кагына да уйнап очып китә
Син яшәгән өйләр ягына.
Ә мин калам тынчу таш төрмәдә,
Тимер рәшәткәгә баш иям.
Өзелергә җитеп сыкрый күңлем
Сагынудан сине, Кадриям!



Хатыны һәм кызлары




Язмыш һаман безне аерырга тырышты һәм менә аерды инде, мәңге күрмәм инде мин аның көләч коңгырт күзләрен...

Урамга чыксам, шинельле кешеләр күрсәм, Фатих исемә төшә. Ах, ул соры шинель... Ах, бу сугыш...




1942 елның мартында Смоленск өлкәсенең Сухиничи, Масалык юнәлешендәге сугышларда була, “Зайцева Гора” биеклеге өчен сугышканда аягы яраланып, госпитальгә эләгә. 1942 елның беренче маенда дәваланып бетү өчен Казан госпиталенә җибәрелә.





18.IV.43 ел.

Кашшаф дус!

**Ф. Кәримнең тәнкыйтьче Гази Кашшафка язган хаты.**

**Г. Кашшаф Ф. Кәримгә яшьлегеннән үк таныш. Бу гомерлек дустына шагыйрь иң тирән серләрен ача, аның киңәшләрен яшәү принцибы итеп ала.**









Ф. Кәрим сугыш елларында гаҗәеп дәрәҗәдә актив эшли. Сугыштан аз гына бушап торган арада да ул 150 дән артык шигырь, 8 поэма, 1 баллада, 2 повесть, 1 драма әсәре иҗат итә.




Җиргә тамган безнең һәр тамчы кан
Кан түгел ул – матур ал чәчәк,
Алар безнең изге җиребездә
Бәхет гөле булып үсәчәк!



Мин – бер шагыйрь; –

тойгы, хис кешесе,

Яратам мин кошлар

сайравын.

Мин – гуманист,

сөям дөньяны,

Акмасын, дип,

җирдә кеше каны,

Гуманизм – минем байрагым.








Алар барысы да шагыйрьне хәтерләтәләр.



“Дөнья хәлләре кискенләшкән саен нигәдер Фатих Кәрим кебек кешеләр искә төшә. Ә бит Фатих Кәрим – Бөек Ватан сугышы шагыйре. Бүгенге дөнья белән узган сугышның арасы нигә шулай якыная? Ике кырыс чор. Татар совет поэзиясендә шул чорны Фатих Кәримнән дә тулырак чагылдырган башка бер шагыйрь дә юк. Кенигсберг янында сугышның бөек үренә күтәрелде, үзенең иҗат үренә күтәрелде, үз шөһрәтенә шул солдат үреннән карап үлде. Үзенә йөкләнгән зур эшне башкарып китте шагыйрь.”

Сибгать Хәким



“Фатих Кәрим – һәр шигырь юлы белән ватанына фидакарь хезмәт иткән җырчы һәм солдат. Аның Казан музеенда изге реликвия булып саклана торган шинеле генә түгел, кульъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән”.

Луи Арагон

optimist@bk.ru



Хәрби кешеләрне күрсәм, әткәй диеп йөзенә карыймын...



Фронтовик-шагыйрь Фатих Кәримгә

100 ел





**Фатих Кәримнең 100 еллык юбилей тантанасыннан.**

**Шагыйрь Ренат Харис һәм Ф. Кәримнең кызы Ләйлә шагыйрьнең кабердә.**





Уфа дәүләт “Нур” татар театры Фатих Кәримнең фаҗигале язмышын гәүдәләндергән “Ясмин гөле” әсәрен сәхнәләштерде. Рәсемнәрдә спектакльдән күренешләр.





Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде.



Ф. Кәрим “Теләк”

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!